ЧӘРШӘМБЕ
31 ГЫЙНВАР
1940 ел
№ 25 (5825)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

МОСКВА, КРЕМЛЬ

ВКП(б) Үзәк Комитеты— иптәш Сталинга СССР Совнаркомы— иптәш Молотовка

Партия һәм хөкүмәт заданиесенең икенче өлеше үтәлде. „Г. Седов“ бозваткыч пароходы Гренландия диңгезе бозларыннан чыгарылды һәм Мурманск портына китерелде. Социалистик Ватаныбызның 15 батыр патриоты совет җиренә кайттылар. 1940 нчы елның 29 нчы январенда 18 сәгатьтә „И. Сталин“ бозваткычы һәм „Г. Седов“ бозваткыч пароходы Мурманск портына килеп туктадылар. „И. Сталин“ бозваткычының материаль часте тулы тәртиптә, экипаж сау-сәламәт, һәм партиянең, хөкүмәтнең теләсә нинди яңа заданиесен үтәве белән үзен бәхетле санаячак.

СССР Совнаркомы янындагы Төньяк Диңгез Юлы Баш Идарәсе начальнигы ПАПАНИН.
„И. Сталин“ бозваткычының капитаны БЕЛОУСОВ.

„И. Сталин“ бозваткычы борты.
1940 ел, 29 январь. Мурманск порты.

Мурманск хезмәт ияләре—иптәш И. В. СТАЛИНГА

Кадерле Иосиф Виссарионович!

Батыр седовчылар, халык геройларының Сталинчыл буынының данлыклы вәкилләре, тагын туган җирдә. Без, социализм иленең төньяк форпосты булган Заполярьеның хезмәт ияләре, җиңүче геройларны илебездә беренче булып каршылавыбыз белән бәхетле һәм горур.

Алар йөзендә без совет халкының сөекле геройларын каршыладык. Ул гына да түгел, алар йөзендә без үзебезнең депутатларыбызны—хезмәт ияләре депутатларының өлкә һәм шәһәр Советлары депутатларын каршыладык.

Без, үзебез белән берлектә бөтен бөек ил үзенең сөекле улларын коча дип хис итәбез.

Седовчылар күңелләрендә Сезнең исмегез булган хәлдә үзләренең легендар батырлыкларын эшләделәр. Сталин дигән бөек исем совет баһадирларын рухландырды, аларны җиңүгә алып барды. Седовчыларның Сезгә, иптәш Сталин, һәм Вячеслав Михайлович Молотовка, героик хәрәкәт тәмам булган көнне юнәлдерелгән сүзләрен без бөтен ил белән берлектә горурлык белән кабатлыйбыз.

...„Илебез, партия һәм иптәш Сталин совет кешеләрен, алар нинди генә кыен шартларда булсалар да, ташламаячакларын без нык рәвештә белдек һәм, үзебезгә тапшырылган эшкә бөтен көчләребезне һәм белемнәребезне биреп, совет фәнен тагын да баетырга тырышып, тыныч эш алып бардык“...

Седовчыларның тирән хис белән әйтелгән бу гади сүзләре 183 миллионлы бөтен совет халкының фикерләрен һәм хисләрен гәүдәләндерәләр.

Седовчыларның үз-үзләрен аямыйча алып барган батыр эшләре совет кешеләренең һәр нәрсәне җиңә торган геройлык үрнәген бөтен дөньяга тагын бер тапкыр күрсәтте. Большевиклар ала алмый торган крепостьларның булмавы турында Сезнең сүзләрегез тагын һәм тагын бер тапкыр расланалар.

Бөек социализм иленең хезмәт ияләре, Ленин—Сталин партиясе җитәкчелегендә, үз юлларыннан барлык дошманнарны себереп ташлап, хезмәт иясе туганнарын капиталистик коллыктан һәм изелүдән азат итеп, бөтен дөнья күләмендә тарихи гүзәл җиңүләргә ирештеләр. Бу көннәрдә седовчыларның батырлыгы белән безнең җиңүләребезнең алтын китабына тагын бер иң күркәкле сәхифә язылды.

Советлар Союзы Герое Иван Дмитриевич Папанин һәм данлыклы котып капитаны Белоусов җитәкчелегендәге „И. Сталин“ флагман бозваткычы экипажының батыр членнарын да без шатлык белән каршыладык.

„Г. Седов“ны боз эчендә хәрәкәт итүдән чыгару операциясе—котып төне һәм кышкы штормнар шартларында эшләнгән бу операция тарихка совет котыпчыларының гаять күркәкле казанышы булып керер.

Без, Мурманск хезмәт ияләре, герой седовчылар белән берлектә Сезгә, кадерле Иосиф Виссарионович, безнең җиңүләребезне рухландыручыга һәм оештыручыга, ялкынлы большевистик сәлам җибәрәбез. Без, җир эче байлыкларын һәм төньяк диңгезләрнең суларын үзләштереп, армый-талмый, большевистик энергия һәм ныклык белән үзебезнең эшебезне алып барабыз, төньяктагы көчле рәвештә ага торган елгаларның энергиясен үзебезгә буйсындырабыз, Төньяк Диңгез Юлын нормаль хәрәкәт итә торган су магистраленә әйләндерәбез. Шушы бөек иҗад эшендә легендар хәрәкәтнең геройлары—безнең җирле Советларыбызның депутатлары актив рәвештә катнаштылар һәм катнашачаклар. Алар белән кулга-кул тотышып эшләү безне яңа җиңүләргә рухландыра.

Безнең Заполярье өлкәсенең гаять зур байлыкларын социализм иленә хезмәткә иң кыска срок эчендә кую өчен, Ватаныбызның хәрби куәтен тагын да ныгыту өчен, ак фин бандаларын тар-мар итү буенча хәрби эштә Кызыл Армиянең Мурманск юнәлешендәге частьләренә һәм Төньяк Хәрби Флотына һәр яклап ярдәм күрсәтеп, тагын да яхшырак һәм ныклырак эш алып барырга Сезгә вагдә бирәбез.

Рәхимсез Арктиканы җиңүче седовчы геройларга дан!

Данлыклы „И. Сталин“ флагман бозваткычы командасына дан!

Бөек коммунистлар (большевиклар) партиясенә дан!

Кешелек дөньясының гаять бөек даһиена — туганыбызга, бөек Сталинга дан!

(Мурманск шәһәре хезмәт ияләренең, „Г. Седов“ бозваткыч пароходының героик экипажын каршылауга багышлап бөтен шәһәр күләмендә 1940 нчы елның 29 нчы январенда җыелган митингысында кабул ителде. Митингта 20 меңнән артык кеше булды).

СОВЕТ ХАЛКЫНЫҢ ГЕРОИК УЛЛАРЫНА

Без, орденлы Татарстанның авыл хуҗалыгы алдынгылары киңәшмәсендә катнашучылар, барлык 183 миллионлы совет халкы белән бергә, батыр седовчыларның Зур Совет җиренә әйләнеп кайтулары уңае белән тирән шатлыкны уртаклашабыз.

„Седов“ хәрәкәтен без зур игътибар белән күзәтеп бардык. Сталин тәрбияләп үстергән кешеләрнең, советның унбиш баһадирының чиксез батырлыгына, аларның рәхимсез табигатькә каршы көрәшенә сокландык. Җиңүнең седовчылар ягында булачагына бер генә минутка да шикләнмәдек. Чөнки алар бөек социализм иленең теләген һәм куәтен, кеше турында Сталинчыл мәхәббәтне һәм кайгыртучанлыкны сизделәр. Сталин исме, безнең барыбызны да көрәшкә һәм җиңүләргә рухландырган кебек, седовчыларны героик батырлык эшенә рухландырды.

Кадерле седовчы иптәшләр! Ватанның данлыгы өчен, коммунизмның данлыгы өчен Сезнең күрсәткән батырлыкларыгыз кешелек дөньясы тарихына алтын хәрефләр белән язылырлар. Сез күрсәткән гайрәтлек һәм батырлык үрнәгендә без, Татарстан колхозларының, совхозларының һәм МТС ларының алдынгылары, табигатькә каршы каты һәм ныклы көрәшкә, нинди генә һава шартларында да Сталинчыл югары иген уңышын яулап алырга, Ватаныбызның куәтен көннән-көн ныгыта барырга өйрәнербез.

Киңәшмә Сезгә ялкынлы сәлам җибәрә һәм совет җиренә кайтуыгыз белән кайнар рәвештә котлый.

Яшәсен совет халкының героик уллары—седовчылар!

Яшәсен социализмның барлык җиңүләрен оештыручы һәм рухландыручы бөек Сталин!

Хуҗалык бурычларын политик эш белән дөрес бәйләп алып барырга

Партиянең производство типындагы башлангыч оешмаларына предприятие администрациясенең эшенә контроль ясау хокукы бирелү—завод-фабрикалардагы, колхозлардагы, совхозлардагы һәм МТС лардагы партоешмаларның рольләрен тагын да югарырак күтәрде, производствода эшләүче коммунистларның активлыкларын һәм җаваплылыкларын көчәйтте. Башлангыч партоешмаларның күпчелеге производство мәсьәләләре белән җиддиерәк шөгыльләнә башладылар. Партия-политик эшне һәм оештыру-масса эшләрен хуҗалык бурычлары белән дөрес бәйләп алып бара башладылар. Бу исә кадрларның тизлек белән үсүләрен, производство планнарының тулы һәм арттырылып үтәлүләрен тәэмин итте һәм итә.

Хуҗалык бурычларын политик эш белән дөрес бәйләп алып баруның хәл иткеч әһәмияткә ия булып торуын күпчелек партоешмалар үзләренең практик эшләрендә ачык күрделәр. ВКП(б) ның XVIII нче съездыннан соң үткән чор эчендә эшнең бу өлкәсендә гаять бай тәҗрибә тупланды. Партия-политик эшне һәм оештыру-масса эшләрен хуҗалык бурычлары белән дөрес һәм нык бәйләп алып баруның гүзәл үрнәкләрен бирүче башлангыч партоешмалар хәзер Татарстан районнарында һәм шәһәрләрендә күпләп саналалар.

Менә Чистай районының Вахитов исемендәге колхоз партоешмасы. Үзенә 15 коммунистны берләштерүче бу оешма политик эшне хуҗалык бурычларына бәйләп алып баруның сокланырлык үрнәкләрен биреп килә. Башлангыч оешма коммунистларны һәм партиясез активны идея-политик яктан тәрбияләү эшен көчәйтү белән бергә, аларны колхоз производствосына дөрес урнаштыру буенча һәм яшь кадрларны җитәкче эшләргә күтәрү буенча зур оештыру эшләре үткәрде. Колхоз җитәкчеләренең, бригадирларның докладларын тыңлауны һәм аларның эшләренә карата чыгарылган карарларның үтәлешен тикшереп баруны үзенең көндәлек эшенә система итеп кертте. Партоешма колхоз эчендә һәм „Бахта“ колхозы белән ике арада социалистик ярыш оештыруның инициаторы булды. Бу чаралар Вахитов исемендәге колхозның алдынгылар сафына чыгуын тәэмин иттеләр.

Яисә менә Мехкомбинат янындагы партоешманың эшен алып карыйк. Башлангыч оешма предприятие администрациясенең эшенә контроль ясау хокукын дөрес тормышка ашыру буенча зур эш башкарды һәм башкара. Шушындый бер мисаль китереп үтәргә мөмкин: партоешма фабрикаларның эшләре белән ныклап танышканнан соң комбинат предприятиеләрендә 1939 нчы ел планын срогыннан элек үтәү мәсьәләсен куйды. Хуҗалык җитәкчеләре, инженер-техник работниклар партоешманың инициативасын бердәм рәвештә якладылар һәм аның тарафыннан билгеләнгән чараларны үтәү көрәшенә туплandылар. Комбинат партоешмасының карары цехларда, бригадаларда, профсоюз, комсомол җыелышларында ныклап өйрәнелде һәм эшчеләр үз өсләренә яңа йөкләмәләр алдылар. Партия-политик эш цехка, бригадага күчерелде, төнге сменаларда агитация-масса эшләре көчәйтелде һ. б. Шушындый эш нәтиҗәсендә, йөзләрчә яңа стахановчылар үсеп чыктылар, партия сафына керергә теләүчеләр саны тагын да артты һәм, ниһаять, комбинат предприятиеләре еллык планны срогыннан элек үтәделәр.

Хуҗалык бурычларын политик эш белән дөрес бәйләп алып баруның мондый гүзәл нәтиҗәләрен бирүче башлангыч партоешмаларны шактый күп санарга мөмкин. Бу фактлардан чыгып шуны әйтергә кирәк: предприятиеләрдәге һәм колхозлардагы башлангыч партоешмаларның иң зур күпчелеге ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарларын дөрес аңладылар һәм съезд тарафыннан үзләренә бирелгән контрольлек хокукын тулы тормышка үткәрү өчен большевистик көрәш алып баралар.

Шуның белән бергә, эшнең бу тармагында яшәп килә торган кимчелекләрне дә күрсәтеп үтәргә кирәк. Партиянең кайбер башлангыч оешмалары предприятие эшенә контроль ясауның төп эчтәлеген әле һаман да ныклап аңлап җиткермәгәннәр. Күпчелек хәлләрдә алар бу эшнең асылын предприятие директорының яки колхоз председателенең докладын тыңлауга гына кайтарып калдыралар. Ә практик булышлык, оештыру эшләре, кадрлар сайлап алу һәм үтәлүне тикшерү мәсьәләләре бер читтә калып килә. Моңа мисаль итеп Автокузовный завод (Казан) янындагы партоешманың эш практикасын күрсәтеп үтү дә җитә. Бу партоешма җитәкчеләре (секретаре—Григорьев) предприятие администрациясенең эшенә контроль ясау турында күп сөйлиләр. Ә чынында исә контроль буенча эффектлы бер нәрсә дә эшләмиләр.

Предприятие администрациясенең эшенә контроль ясауны тормышка ашыру—ул, барыннан да элек, производствода эшнең яхшыруында, дәүләт тарафыннан йөкләтелгән бурычларның уңышлы үтәлүендә күренергә тиеш. Моңа ирешү өчен, иң беренче чиратта, хуҗалык бурычларын политик эш белән дөрес бәйләп алып бару, кадрлар сайлап алу һәм үтәлүне тикшерү мәсьәләләрен көндәлек эшкә система итеп кертү таләп ителә. Ниһаять, моның өчен, партиясезләр массасы белән ныклы элемтәдә булу, партия һәм хөкүмәт карарларын үтәү көрәшенә киң массаны туплау һәм массаның иҗад активлыгына большевистик җитәкчелек таләп ителә.

Бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин безне болай дип өйрәтә: „Политиканы хуҗалыктан аерырга ярамый. Без, политикадан китә алмаган шикелле, хуҗалыктан да китә алмыйбыз. Өйрәнергә уңайлы булсын өчен, кешеләр гадәттә, хуҗалык мәсьәләләрен политика мәсьәләләреннән методология ягыннан аералар. Ләкин бу тик методология ягыннан, ясалма рәвештә, өйрәнергә уңайлы булсын өчен генә эшләнә. Тормышта, киресенчә, практикада политика һәм хуҗалык бер-берсеннән аерылгысыз. Алар бергә яшиләр һәм бергә хәрәкәт итәләр“.

Предприятие администрациясенең эшенә контрольне менә шушы тарихи күрсәтмәдән чыгып оештырырга кирәк. Хуҗалык мәсьәләләренә дөрес караш урнаштырырга, программаны үтәүдә һәм арттырып үтәүдә хуҗалык работникларына ярдәм итәргә, аларны үзләренең эшләрен политик бурычлар белән дөрес бәйләп алып барырга өйрәтергә кирәк. Партия-политик эшнең һәм оештыру-масса эшләренең куелышы социалистик хуҗалыкның барлык тармакларында дәүләт йөкләмәләренең тулы үтәлүен тәэмин итсеннәр, кадрлар идея-политик яктан һәм практик эш ягыннан туктаусыз үссеннәр, массаның политик һәм производство активлыгы тулы көченә яңгырасын. Партия оешмаларыннан әнә шулар таләп ителә.

Мурманск хезмәт ияләре иптәш—В. М. МОЛОТОВКА

Кадерле Вячеслав Михайлович!

Мурманск хезмәт ияләре, социалистик Ватанның седовчы 15 батыр улын каршылауга багышлап бөтен шәһәр күләмендәге митингга җыелган хәлдә, сезгә—бөек Сталинның иң якын көрәштәшенә, Совет Хөкүмәте башлыгына, кайнар большевистик сәлам җибәрәләр.

Мурманск өлкәсенең большевиклары Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) Партиясе җитәкчелегендә Кола ярым атавын безнең социалистик Ватанның төньяктагы какшамас форпостына әйләндерделәр. Бөек Сталин тарафыннан рухландырылган хәлдә без өлкәдәге хуҗалыкның тиз рәвештә үсүен, киң массаларның тормыш дәрәҗәләре үсешен тәэмин иттек. Советның трал һәм арктик флотларын үстерү өстендә, Кола ярым атавының чиксез байлыкларын үзләштерү өстендә без армый-талмый эшләдек һәм эшлибез. Мурманскийда һәм Мурманск өлкәсендә, безнең чәчәк атучы бөтен илебездәге шикелле үк, атаклы кешеләр армиясе, иҗад итүче геройлар армиясе, партиягә, Ватанга, иптәш Сталинга чиксез дәрәҗәдә чын күңелдән бирелгән кешеләр армиясе үсә.

Арктиканы үзләштерү өчен көрәш тарихына үзләренең батырлыклары белән данлыклы сәхифәне язган батыр тикшеренүчеләрне без әйтеп бетерә алмаслык зур шатлык һәм горурлык хисе белән каршыладык.

Социализм дошманнарын тармар иткән һәм юк иткән 183 миллионлы халкы булган илебездә, Көнбатыш Украинадагы һәм Көнбатыш Белоруссиядәге хезмәт иясе туганнарыбызга азатлык китергән илдә, социализм даны өчен искиткеч һәм гүзәл җиңүләр саны көннән-көн үсә.

Седовчыларның батырлыгы, бозлар арасында хәрәкәт итү шартларында, котып төне, көчле штормнар шартларында аларның үз-үзләрен аямыйча хезмәт күрсәтүләре кешелек дөньясы тарихына Сталин эпохасының данлыклы эпопеясе булып, прогрессив фәнгә кыйммәтле хәзинә булып керәчәк.

Социализм төзүче буыннар кыенлыкларга каршы ничек көрәшергә, куелган теләккә кыю рәвештә барырга һәм җиңәргә седовчыларның батырлыкларыннан өйрәнерләр.

Без, Мурманск шәһәре һәм бөтен Мурманск өлкәсе хезмәт ияләре, седовчылар шикелле үк, үзебезнең коммунистлар партиясе һәм иптәш Сталин җитәкчелегендә, безнең алга партия һәм хөкүмәт тарафыннан куелган бурычларны тулысынча тормышка ашыру өчен киләчәктә дә ныклы көрәш алып барырбыз. Кола ярым атавында чиксез дәрәҗәдә булган җир байлыкларын, төньяк диңгезләре һәм елгалары байлыкларын тулысынча үзләштерүгә ирешербез. Без, кыенлыкларны җиңеп, бөек Ватаныбызның хәрби куәтен көннән-көн ныгытырбыз, героик Кызыл Армиябезнең һәм Төньяк Хәрби Флотының хәрби сәләтен ныгытырбыз.

Яшәсен эшче һәм крестьяннәрнең дөньяда беренче булган социалистик дәүләтенең Хөкүмәте!

Яшәсен бөек Сталинның турылыклы көрәштәше, Хөкүмәт башлыгы Вячеслав Михайлович Молотов!

Яшәсен безнең җиңүләрнең байрагы, юлбашчыбыз, атабыз һәм остазыбыз бөек Сталин!

Рәхим итегез, кадерле батырлар!

Озак вакыт буена сузылган боз тоткынлыгыннан азат ителгән „Г. Седов“ бозваткычының героик экипажына һәм аны азат итүчегә—„И. Сталин“ бозваткычының данлыклы коллективына чын күңелдән сәлам һәм котлау җибәрәм.

Үзебезнең Зур Җиребезгә кайтуыгызга бөтен ил белән берлектә шатланам, дуслар.

Фаҗигале һәлакәткә очраган Георгий Седов исме белән аталган бозваткычны бөтен илебезнең сөеклесе Иосиф Виссарионович Сталин исме белән аталган совет арктика флоты флагманының коткаруы минем өчен аеруча зур шатлык.

Рәхим итегез, кадерле батырлар!

В. В. Седова.

Ленинград, 29 январь. (ТАСС).

РӘСЕМДӘ: Иван Дмитриевич Папанин радиорубкада седовчылар белән сөйләшә. Д. Дебабов фотосы (ТАСС фото - клишесе).

БАТЫРЛАРГА СӘЛАМ

Геройлык совет кешесенә хас нәрсә. Производствода стахановча эшләп һәм илебезнең байлыкларын арттырып, стихияне җиңүгә ирешеп, хезмәт ияләренең дошманнарына каршы данлыклы көрәш алып барып, безнең илдә һәр кеше герой була ала. Совет иленең патриотлары арасында геройлык күрсәтүнең чиге юк!

Моннан ике елдан артык элек „Седов“ бозваткычы экипажы Арктиканың өйрәнелмәгән һәм дәһшәтле көчләренә каршы көрәш башлады. Сталинның кайгыртучанлык күрсәтүе белән рухландырылган совет кешеләре, гади кешеләр бу көрәштә чыдамлык могҗизаларын күрсәттеләр. Алар котыпның озын төннәре шартларында Ватаныбызның байрагын лаеклы рәвештә күтәреп үттеләр.

Бүген, седовчы геройлар озак вакыт хәрәкәттә булганнан соң, туган җиргә яңадан аяк баскач, куәтле Ватан үзенең лаеклы улларын шатлык белән котлый һәм коча.

Котып батырлары турындагы данлылык гасырлар буе яшәр. Аларның батырлыклары социализмның җиңүләре тарихына данлыклы сәхифәләр булып керерләр. Седовчыларның образлары Совет сәнгатенең тәэсирләндерүче яңа әсәрләрендә гәүдәләнерләр.

С. Эйзенштейн.

Атказанган сәнгат эшлеклесе.

СЕДОВЧЫЛАРНЫҢ БАТЫРЛЫГЫ ТУРЫНДАГЫ ДАН МӘҢГЕ СҮНМӘС

Седовчыларның, куркусыз сталинчыл морякларның исемнәре тарихка керде. Аларның батырлыклары турындагы дан мәңгегә сүнмәс. Алар чиктән тыш батырлык, кыюлык, салкын канлылык үрнәкләре күрсәттеләр. Карабны сытарга һәм батырларны диңгез төбенә алып китәргә һәрбер минутта хәзер торган мәкерле Арктика стихиясенә каршы аларның героик көрәше 812 көн дәвам итте. Караңгы котып төненең авыр шартларында, Арктика җәеенең томанлы көннәрендә, кар буранында һәм каты салкыннарда алар үзәк Арктиканың серләренә төшенү өчен, бөек Төньяк Диңгез юлын үзләштерү өчен беренче дәрәҗәле әһәмияте булган фәнни тикшеренүләрне армый-талмый алып бардылар.

Бер-бер артлы булган боз атакаларына седовчылар Сталин исме белән бардылар. Алар хәрәкәтнең иң башыннан ук Совет халкының бөек мәхәббәте белән чолганып алынганнар иде һәм бу мәхәббәт аларны рухландырды һәм елытты. Максатның ачык булуы, ныклык аларның гүзәл җиңүләрен тәэмин итте.

„Седов“ экипажының батырлыгына барлык Совет гражданнары соклаңалар. Аларның үрнәге юлдагы кыенлыкларны ничек җимерергә, дошманны ничек җиңәргә, сөекле Ватаныбыз хакына ничек батыр эшләр эшләргә кирәклеккә өйрәтә. Барлык Совет кешеләре, седовчылар кебек үк, туган җиребезне батырларча, лаеклы рәвештә һәм намус белән сакларга хәзер торалар.

Без, Ватаныбызның дошманнарына каршы күп тапкырлар сугышкан, һавадагы дошманны күп тапкырлар тар-мар иткән очучылар, седовчыларның батырлыклары алдында баш иябез.

Сезгә, иптәшләр, туган җиребезгә геройлар булып кайткан седовчыларга дан!

Советлар Союзы Герое комкор
Я. В. СМУШКЕВИЧ

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

29 нчы январьда фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмады.

Безнең авиация разведка очышлары һәм хәрби очышлар үткәрде, төрле районнарда дошманның 7 самолеты бәреп төшерелде.

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсендә

Иптәш Москвин реченнән

(Куйбышев тәҗрибә кыры мөдире)

Татарстан АССР шартларында, бигрәк тә аның көньяк һәм көньяк-көнчыгыш районнарында, туфракта дым туплау мәсьәләсенә аеруча зур игтибар бирелергә тиеш. Чөнки туфракта дым туплау иген уңышын күтәрү өчен көрәштә хәл иткеч чараларның берсе булып тора. Моның шулай икәнен алдынгы колхозларның, совхозларның һәм, ниһаять, ефремовчыларның тәҗрибәләре бик ачык күрсәтә.

Ләкин бездә әле туфракта дым туплау мәсьәләсенә җитәрлек әһәмият бирелми. Кар тотуны алыйк. Күп. кенә урыннарда кар тоту дөрес үткәрелми. Авыл хуҗалыгы алдынгыларының һәм тәҗрибә станцияләренең тәҗрибәләре карны щитлар һәм кулис ярдәме белән тотуның бик яхшы нәтиҗәләр бирүен күрсәтәләр. Мин кар бик аз төшкән 1936 нчы елгы кышны алам. Бу кышта безнең Куйбышев тәҗрибә кыры басуларында кар тотылмаган урыннарда карның калынлыгы бары 13—16 сантиметр иде. Шахмат тәртибендә щитлар куйган участкыларыбызда карның калынлыгы 45—50 сантиметрга, ә кулис кулланган участкыларда 50—55 сантиметрга җитте.

Шуңа күрә мин һәрбер колхозда щит хуҗалыгын тәртипкә салуга аеруча игтибар бирергә киңәш итәм.

Республикабызның көньяк һәм көньяк-көнчыгыш районнарында кулислы парларга җидди игтибар бирелергә тиеш. Ә бездә бу нәрсә соңгы вакытларда онтылды дип әйтерлек.

Элек вакытларда кулислар пар җирен машина белән эшләргә тоткарлык ясый иде һәм икенчедән кулис өчен чәчелгән көнбагыш пар җирләрен киптерә иде. Хәзер кулис пары мәсьәләсендә эш икенче төрлерәк куела. Пар җиренә кулис өчен көнбагыш яздан түгел, ә июль ае башларында чәчелә. Көзгә кадәр бу көнбагыш 25—30 сантиметр биеклеккә үсеп җитә, парны эшләгән вакытта механизмнарга бу нәрсә һич тә тоткарлык ясамый. Ә көзге суыклар башланганчыга кадәр бу көнбагыш 50—55 сантиметр биеклеккә җитә.

Минераль ашламалардан файдалану буенча бер-ике сүз. Бездә минераль ашламаларны (мин барлык фосфоритларны алам) тик сабан ашлыклары астына гына кертергә кирәк дип әйтәләр. Әдәбиятта да шулай күрсәтелә. Болай эшләргә киңәш бирүне, бигрәк тә безнең көньяк һәм көньяк-көнчыгыш районнарыбыз өчен, мин дөрес түгел дип исәплим. Менә фосфоритлар буенча берничә сан. 1929 нчы елда кыш бик салкын булды. Ул елны Татарстан АССР да һәм Союзның Европа өлешенең күпчелегендә уҗымнар кышкы суыкларда һәлак булдылар. Шул елны безнең тәҗрибә кырында да минераль ашлама кертмәгән, чиста парга чәчелгән арыш гектарыннан бары 4,57 центнер уңыш бирде, ә пар җиренә суперфосфат кертелгән участкыларда уңыш 11,36 центнер чыкты. Уҗымнар өчен бик начар килгән 1938—39 нчы елда безнең көньяк һәм көньяк-көнчыгыш районнарында уҗымнарның 50—70 проценты һәлак булды. Безнең тәҗрибә кырында шул елны ашлама кертми чәчкән участкыларда арышның гектарыннан 13,42 центнер, ә суперфосфат кертелгән участкыларда 17,26 центнер уңыш чыкты. Дым ягыннан бик ярлы булган 1930 нчы елны алыйк. Бу елда да суперфосфат гаять зур роль уйнады. Суперфосфат кертмәгән участкыларда гектарыннан бары 12,47 центнер арыш уңышы чыккан булса, суперфосфат белән ашланган участкылар һәр гектардан 24,5 центнер уңыш бирделәр.

Игеннәрне ясалма сугару турында берничә сүз. Киләчәктә, Куйбышев гидроузел төзелеше эшли башлау белән бездә игеннәрне ясалма сугару эше белән күп кенә районнарыбызда бик җидди рәвештә шөгылләнергә туры киләчәк. Моны хәзердән үк искә алырга һәм игеннәрне ясалма сугару эшен киләчәктә киң күләмдә җәелдерү өчен нык хәзерлек алып барылырга тиеш. Игеннәрне ясалма сугаруның файдасы гаять зур. Безнең тәҗрибәләребездән менә берничә факт. Без 1939 нчы елны ясалма сугару үткәрелмәгән участкыларда гектарыннан 26,5 центнер уңыш алдык, ә сугару үткәрелгән участкыларыбыз 52,2 центнер уңыш бирделәр.

Татарстан АССР ның күп районнарында игеннәрне ясалма сугару эшен хәзер үк киң күләмдә үткәрергә мөмкинлек бар. Куйбышев районында да ике елга бар. Ясалма сугару өчен бу елга суларыннан бик җиңел итеп һәм арзанга төшереп файдаланырга була. 1934—35 нче елларда бу елгаларга чыгырлар һәм насослар куеп яшелчәләрне сугарганнар иде һәм күп кенә колхозлар шул елларда яшелчә буенча бик яхшы уңыш алганнар иде. Ләкин соңгы елларда бу нәрсә онтылды. Күп колхозларда чыгырлар ташландык хәлдә ята. Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариаты иген уңышын күтәрү буенча бу көчле чараны тормышка ашыру белән нык шөгылләнергә тиеш.

Иптәш Дәүләтшин реченнән

(Тымытык МТС комбайнчысы)

Иптәшләр! Иң элек сезне Тымытык МТС работниклары исеменнән котларга рөхсәт итегез. **(Кул чабулар).**

Мин 1937 нче елдан бирле комбайнчы булып эшлим. Минем комбайным елдан-ел югары эш күрсәткечләре бирә. 1938 нче елны „Коммунар“ комбайнында 25 эш көнендә 400 гектар, сезонга 600 гектар урып-җыюны йөкләмә итеп алган идем. Бу йөкләмәне үтәдем. Сезонга 600 гектар урнына 915 гектар эшләдем. 1939 нчы елда да комбайн белән 985 гектар эшләдем. 1938 нче елда ягулыкка 4 центнер, 1939 нчы елда 6 центнер экономия ясадым.

Минем комбайн гына түгел, гомумән, безнең МТС тагы комбайннар яхшы эшләделәр. 1938 нче елда МТС тагы һәрбер комбайн уртача 415 гектар, 1939 нчы елда инде 447 гектар эшләде.

Комбайннарның яхшы эшләүләренә без ничек ирештек соң?

Без моңа, барыннан да элек, комбайннардан яхшы файдалану, машинаның барлык серләрен өйрәнү, аңа үз вакытында техник уход үткәрү һәм профилактик чаралар үткәрү нәтиҗәсендә ирештек.

Комбайн белән эшләү өчен участкылар сайлап алу комбайнның яхшы эшләвендә хәл иткеч моментларның берсе булып тора. Кагыйдә буларак, мин яздан ук үземә участкылар сайлап алам һәм бу участкыларда чүп үләннәре үсмәсен өчен аларны җәй буена тикшереп торам. Минем комбайным урып-җыячак участкыларда чүп үләннәре чыга башлаганны күрсәм, шул ук вакытта аларны утау эшен оештырам.

Комбайн агрегаты өчен кешеләрне алдан сайлап алу комбайнның яхшы эшләвендә зур урын тота. Агрегатка кешеләрне мин һәр вакытта иң яхшы колхозчылар арасыннан сайлап алам. Алар эш башланганнан алып, эш тәмам булганга кадәр агрегатта эшлиләр. Шулай итеп, эш көче җитмәүдән, вактында су бирмәүдән һәм башкалардан килеп чыгуы мөмкин булган эшсез торуларга алдан ук чик куела.

Хезмәт дисциплинасын һичбер вакытта да бозмау—эшкә үз вактында чыгу, эш көненнән тулысынча файдалану комбайнның тулы нагрузка белән эшләвен тәэмин итә. Мин үзем иртүк эшли башлау өчен комбайнны төннән үк көйләп куям һәм тулы көн буе эшлим. Бункердагы ашлыкны, комбайнны туктатмыйча гына, капчыкка бушаттырам. Бу, комбайнның җитештерүчәнлеген күтәрә.

Эшне шулай кую һәм комбайнның яхшы эшләве нәтиҗәсендә мин үзем дә яхшы материаль шартларда, культуралы, таза тормышта яшим. Мин сезонга 10 мең сумнан артык хезмәт хакы алдым. Белемемне күтәрү өстендә эшлим, машинаны, гомумән техниканы өйрәнәм.

Яшәсен, безне зур уңышларга алып килүче, колхоз кадрларын тәрбияләп үстерүче, халыкларның бөек юлбашчысы даһи Сталин! **(Көчле кул чабулар.)**

Иптәш Әглямов реченнән

(Актаныш МТС ының трактор бригадасы бригадиры)

Актаныш МТС ы 1939 нчы елны трактор паркыннан файдалану һәм колхоз кырларының уңышын күтәрү буенча гаять зур уңышларга иреште. 15 ат көчле тракторга күчереп исәпләгәндә һәрбер трактор 1.029 гектар җир эшләде. Ә безнең бригада 1.390 гектар эшләде һәм ягулыкка 4.340 килограмм экономия ясады.

МТС коллективының бу уңышлары партиябезнең һәм хөкүмәтебезнең көндәлек кайгыртучанлык күрсәтүе һәм хезмәтне оештыруга җидди игтибар бирү нәтиҗәсендә яулап алынды.

Без эшкә ремонт кампаниясенең башыннан ук ныклап тотындык. Бригададагы тракторчылар барсы да үзләренә беркетелгән тракторларга ремонт ясадылар һәм бригадир да ремонт эшенә катнашты. Шул ук вакытта тагылма инвентарьларны төзәтүгә зур игтибар бирелде. Ремонт вактында һәм шулай ук кыш көне машиналарны техник яктан карауда бөтен кагыйдәләр нык күзәтелде.

Хезмәтне дөрес оештыру һәм хезмәт дисциплинасы эшнең уңышлы баруын хәл итә. Безнең бригада прогулның нәрсә икәнлеген дә белми. Бездә тракторчылар тарафыннан эшкә соңга калу һәм прогул ясау фактлары булганы юк. МТС тагы барлык бригадалар үзара социалистик ярыш оештырдылар. Безнең бригада 7 нче бригада белән ярышты һәм беренчелекне алды. Бригада членнарыннан иптәш Фазлеев үз сменасында 817 гектар, ә иптәш Хәбибуллин 688 гектар эшләделәр. Бригадабыз МТС күләмендә беренче урынны алса, алар бригада эчендә беренчелекне алдылар.

Тракторчылар яхшы эшләсеннәр өчен аларга кирәкле бөтен шартларны булдырырга кирәк. Бездә бригадаларда культура ягыннан хезмәт күрсәтү эшенә нык әһәмият бирелде: культвагоннар оештырылды. Алар газета-журнал, китап, музыка кораллары белән тәэмин ителделәр.

Безнең 1939 нчы елны ирешкән уңышларыбыз әле алар башлангыч уңышлар гына. 1940 нчы елда без ефремовчылар тәҗрибәсен нык кулланып, колхозларыбызда һәр гектардан кимендә 100 пот иген уңышы алу өчен көрәшербез. 15 ат көчле тракторга күчереп исәпләгәндә һәр трактор белән 1.500 гектар һәм һәр комбайн белән 500 гектар эшләү өчен, ягулыкка кимендә 10 процент экономия ясау өчен көрәшербез. Бу бурычны, һич шиксез, намус белән үтәрбез.

Иптәш Домнина реченнән

(Акташ районы, Чумаков исемендәге колхозның киндерчелек звено башлыгы)

Иптәшләр! Мин киндер үстерү буенча үзебезнең колхоз практикасыннан кайбер тәҗрибәләр турында сөйләмәкче булам.

Безнең колхоз оешкан елларыннан бирле киндерчелек эше белән шөгылләнеп килә. Ләкин 1937 нче елга кадәр без ел саен 40 гектар чәчүгә карамастан, бу культурадан канәгатьләнерлек уңыш алмадык. Алган сүс хәтта колхоз кирәкләренә дә җитми иде.

1937 нче елда колхоз мине киндерчелек буенча звено башлыклары хәзерләү курсына җибәрде. Шул елны 1 гектар киндер чәчтек. Җирне тирес һәм минераль ашламалар белән ашладык. Киндер тишелеп чыккач, кирәкле тәрбия чаралары үткәрдек. Шулай эшләү нәтиҗәсендә ул елны киндернең бер гектарыннан 5 центнер сүс уңышы алдык, дәүләт алдындагы йөкләмәне 100 процент үтәдек.

Шуннан соң без тиешенчә эшләгәндә киндердән югары уңыш алырга мөмкин булуын үзебез күрдек.

1938 нче елда 30 гектар киндер чәчтек һәм 4 звено оештырдык. Минем звенода 4 кеше иде. Колхоз буенча уңыш һәр гектардан уртача 4 центнер булды, ә безнең звено участкысында, агротехника чараларын вактында һәм төгәл үткәрү, йолкып җыюны югалтусыз кыска срокта төгәлләү нәтиҗәсендә уңыш гектарга 6 шар центнерга җитте. Колхозда дәүләткә сүс тапшыру планы 300 процент, минем звенода 1.200 процент үтәлде. Планны арттырып үтәгән өчен түләнгән премия звено членнары арасында тагын да зур дәрт тудырды.

Үткән ел киндер мәйданын 35 гектарга җиткердек. Бу участкыларда эшләү өчен 8 звено оештырылды. Минем звенога 4,5 гектар беркетелгән иде. Без ел да үткәрелә торган чаралардан тыш үткән ел бер гектарда тукландыру үткәрдек. Серкәләнү вактында көннәр бозылып киткәнлектән безгә гади ысул белән серкәләндерү чаралары кулланырга туры килде. Шулай итеп, без башка звеноларга караганда зуррак уңыш алдык һәм планны 160 процент үтәдек. Мин үткән ел Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнаштым.

Шуны әйтергә кирәк, әле байтак колхозларда техник культураларга бәя биреп җиткермәүчелек хөкем сөрә. Бу хәл безнең колхозда да бар. Звено членнарын башка эшкә күчерү, кирәк вакытта тарту көчләре бирмәү кебек фактлар еш кабатлана. Мәсәлән, шундый сәбәпләр аркасында 1937 нче елда киндерне йолкып җыю вактында безгә жалоба белән район башкарма комитетына кадәр җитәргә туры килде. Үткән ел да колхоз правлениесе звенодагы бер кешене башка эшкә алып куйды.

Техник культураларга карата мондый бәя бирмәүчелек кичекмәстән бетерелергә тиеш.

Без быел үз звенобызга беркетелгән участкыларда һәр гектардан 8 центнер уңыш алырга йөкләмә алдык. Без бу йөкләмәбезне тулысынча үтәвебезгә нык ышанабыз. Моның өчен хәзер барлык чараларны күрәбез.

Яшәсен коммунистлар партиясе һәм аның юлбашчысы бөек Сталин! **(Кул чабулар).**

Ярышта өстен чыгу өчен

(Мордовия АССР Наркомземының баш агрономы иптәш Мельников реченнән)

Иптәшләр! Татарстанның авыл хуҗалыгы алдынгыларына һәм белгечләренә Мордовия республикасының колхозчыларыннан, колхозчы хатын-кызларыннан һәм барлык хезмәт ияләреннән большевистик ялкынлы сәлам тапшырырга рөхсәт итегез. **(Кул чабулар).**

Иптәшләр! Моннан 2—3 ел элек авыл хуҗалыгында стахановчылар саны бик аз иде. Ә хәзер алар бик күп, безнең илебездә алар миллионлап саналалар. Социалистик авыл хуҗалыгында стахановчылык хәрәкәтенең кызу рәвештә үсүенең сәбәбе нәрсәдә соң?

Аның сәбәбе шунда: беренчедән, колхоз төзелеше тәмам җиңде. Икенчедән, партиябез, хөкүмәтебез һәм иптәш Сталин колхозлар турында, барлык колхозчылар турында көндәлек рәвештә кайгыртучанлык күрсәтәләр. Партиябез һәм хөкүмәтебез авыл хуҗалыгы алдынгыларының эшенә гаять югары бәя бирәләр, аларны тагын да зуррак уңышларга рухландыралар.

Авыл хәзер танымаслык булып үзгәрде: аның киң кырларында ун һәм йөз меңнәрчә тракторлар, комбайннар һәм башка эре машиналар эшлиләр. Катлаулы машиналарны үзләштергән гүзәл кадрлар, авыл хуҗалыгы белгечләре үсеп чыктылар. Безнең илебездә социалистик авыл хуҗалыгын минераль ашламалар белән тәэмин итүче химия промышленносты үсеп чыкты. Бу чаралар социалистик кырларның уңыш бирүчәнлеген арттыруның көчле коралы булдылар.

Иптәшләр! Мин агрономнарның эшләре турындагы мәсьәләгә тукталып үтмәкче булам. Җир органнарының эшләрен тамрыннан үзгәртеп кору турында партиябезнең һәм хөкүмәтебезнең карары гаять зур әһәмияткә ия булып тора һәм агрономнардан бу өлкәдә җидди эш таләп ителә.

Мордовия республикасының авыл хуҗалыгы белгечләре үз киңәшмәләренең берсендә, колхозларга оператив җитәкчелек итүне көчәйтергә, стахановчы звенолар оештыру эшенә якыннан катнашырга дигән карарга килделәр. Безнең республикабызда барлыгы 500 агроном бар, шулардан 8 кеше генә Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнаша алды. Бу хәл бездә әле агрономнарның начар эшләүләрен күрсәтә. Кайбер агрономнарның производстводан аерылу фактлары да сер түгел. Бездә 10—15 ел аппаратта утыручы, кәгаз язып вакыт үткәрүче агрономнар да бар. Билгеле, мондый агрономнар хәзер безнең стахановчыларыбыздан артка калдылар.

Район җир бүлекләренең һәм наркомзем аппаратының агрономнары производствога якын килергә, югары уңыш алу мәсьәләләре белән турыдан-туры үзләре шөгылләнергә тиешләр.

Иптәшләр! Бу киңәшмәдә Мордовия һәм Чувашстан республикалары вәкилләре катнашалар. Бездә, Мордовия республикасында, техник һәм бөртекле культуралар үстерү буенча зур уңышларга ирешкән колхозлар аз түгел. Менә берничә мисаль.

Чкалов исемендәге колхоз, климат шартларының беркадәр начар булуына карамастан, 1938, 1939 нчы елларда бөртекле культуралар чәчелгән 200 гектар мәйданда һәрбер гектардан уртача 12,9 центнер уңыш алды. Буденный исемендәге колхоз 400 гектар мәйданда 2 ел буена һәрбер гектардан уртача 12,5 центнер, „Кызыл Байрак“ колхозы 200 гектар мәйданда һәрбер гектардан уртача 13 центнер уңыш алдылар. Ксения Миронованың звеносы 10 гектар мәйданда сабан бодаеның һәрбер гектарыннан 25 центнер уңыш алды.

„Коммунар“ колхозы 1939 нчы елда киндер сүсен һәрбер гектардан 15 центнер, „Красный мир“ колхозы шулай ук көньяк киндеренең гектарыннан 17 центнер уңыш алдылар. Повылкино районының „Коммунар“ колхозының аерым звенолары бигрәк тә зур уңыш алуга ирештеләр. Мәсәлән, Уразова звеносы тәмәке чәчелгән 5 гектар мәйданда һәрбер гектардан 40 центнер тәмәке уңышы алды.

Аерым колхозлар, бригадалар яхшы күрсәткечләргә ирештеләр, ләкин шулай да Мордовия республикасы Чувашстан АССР белән социалистик ярышта артка калды. Бу 1939 нчы елның эш йомгакларында ачык күренә. Мәсәлән, Мордовия республикасында 1939 нчы елда кырга тирес чыгару планы 70 процент үтәлде. Яровойлаштырылган орлык белән чәчү планы 76 процент үтәлде. 1939 нчы елда кар тоту планы 28 процент кына үтәлде. Тракторлар паркының эш планы республика буенча 85 процент үтәлде. Билгеле, яхшы эшләгән аерым МТС лар булды. Ләкин без андый алдынгы МТС ларның эш тәҗрибәләрен башкаларга күчерә алмадык. Безнең бурыч—1940 нчы елда 1939 нчы елгы хаталарны кабатламаудан, булган кимчелекләрне тиз арада бетерүгә ирешүдән гыйбарәт.

Без язгы чәчүгә ничек хәзерләнәбез? Бу өлкәдә дә әле эшнең темпын кызулатасы бар. 20 нче январьга кайбер саннар менә түбәндәгечә: кузаклы культуралар буенча орлык туплау планы 60 процент, орлык чистарту—30 процент, авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау планы 50 процент, тракторларга капиталь ремонт 40 процент, агымдагы ремонт 43 процент үтәлде.

Сез, иптәшләр, Мордовия Автономияле Совет Социалистик Республикасын социалистик ярышка чакырдыгыз. ВКП(б) ның Мордовия Өлкә Комитеты һәм Мордовия республикасы хөкүмәте Сезнең чакыруыгызны кабул иттеләр һәм орденлы Татарстанның авыл хуҗалыгы алдынгыларының шушы киңәшмәсендә катнашу өчен 5 кешелек составта делегация җибәрделәр. Мордовия республикасының хезмәт ияләре, Сезнең белән социалистик ярышка чыккан хәлдә, Сталинчыл югары иген уңышы алуда яхшы күрсәткечләргә ирешерләр.

РӘСЕМДӘ: авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсенә Мордовиядән килгән кунаклар. Сулдан уңга—С. Г. Мельников, Р. М. Яськин, Н. Г. Лапин һәм Л. Байчурин иптәшләр.

М. Солтанов фотосы.

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсендә

Иптәш Прохоров реченнән

(Татнаркомземның агротехника һәм механизация идарәсе начальнигы)

Иптәшләр! Мин үз чыгышымда агротехника чараларын үткәрүнең әһәмияте турында сөйләргә уйлыйм. Бер гади мисаль алыйк. Әгәр дә терлекләргә, мәсәлән, сыерга яхшы бинаны, яхшы тукландыруны, яхшы карауны тәэмин итсәк, һәр кемгә билгеле булганча, сыер таза булачак, күп сөт бирәчәк. Ләкин, иптәшләр, әгәр дә шул ук сыерны начар туйдырсалар, вактында эчермәсәләр, начар бинада тотсалар, билгеле, бу сыер—начар сыер булачак. Бу гадый мисаль үсемлекләр мисалендә тагын да ачыграк күренә. Әгәр дә без һәрбер чараны үз вактында үткәрсәк безнең үсемлекләр яхшы булачак, әгәр дә инде без аны эшләмәсәк, без югары уңышны ала алмабыз. Яхшы иген уңышы алу өчен, иң беренче чиратта, туфракта яхшы структура булдырырга, аны чүп үләннәрдән яхшылап чистартырга кирәк.

Үсемлекләрне яхшы тукландыру—ул, беренчедән, туфракны яхшы чергән тирес һәм башка җирле ашламалар белән ашлау, икенчедән, туфракка минераль ашламалар кертү, өченчедән, өстәмә тукландыру һәм, дүртенчедән, кар тоту, кар суын тоту һәм сугару юлы белән туфракта дымны саклау.

Аннары, үсемлекләрне яхшы тәрбия итү—ул, барыннан да элек, киң рәтле итеп чәчелгән культураларның һәм сызма культураларның рәт араларын үз вактында һәм яхшы сыйфатлы итеп эшкәртү, үз вактында утау һәм корткычларга каршы көрәш. Югары иген уңышы алуны тәэмин итәрлек чаралар комплексы әнә шулар. Бу чараларны үз вактында һәм тулы рәвештә үткәргәндә генә югары уңышка ирешергә мөмкин. Әгәр дә без берике чараны яхшы үткәреп тә, башкаларын начар, яки бөтенләй үткәрмәсәк, билгеле яхшы уңыш көтә алмыйбыз. Мин безнең авыл хуҗалыгы алдынгыларының, колхозчыларның игтибарларын нак менә шуңа юнәлдерергә уйлыйм, чөнки әгәр дә үсемлекләргә ашламаны тулысынча биреп тә, җирдә дымны сакламасак, без югары уңыш ала алмыйбыз, һәм киресенчә, җирдәге дымны без никадәр генә сакласак та, әгәр дә үсемлек тиешле ашламаны ала алмаса, ул вакытта үсемлек ашлама нәрсәләренең минимумы белән генә чикләнәчәк. Димәк, югары иген уңышы алу өчен көрәштә агрономия чараларының бөтен комплексын тулысынча үткәрергә кирәк.

Бездә бу мәсьәлә белән эш ничек тора соң? Бер мисаль китерәм. Әлки районы колхозлары 1939 нчы елда агрономия чараларын түбәндәгечә үткәрделәр: камылны лущит итү—0 процент, туңга сөрү планы 1 нче октябрьгә, ягни агротехника срогына—33 процент, ә калганнары агротехника срогыннан соң үтәлә, кара пар—0 процент, ягни бөтенләй үткәрелми, иртә пар, шулай ук, 50 процент кына үтәлә. Тирес чыгару—81 процент, кош тизәген җыю—94 процент, тирес сыекчасы җыю—4 процент, компост ашлама хәзерләү—0 процент, туфракка көл кертү—49 процент, кузаклы культураларны нитрагинлаштыру — 5 процент, бөртек ашлыкны яровойлаштыру—96 процент, кар тоту—96 процент, ужым тырмалау—32 процент үтәлә. Язгы чәчү 40 көнгә сузыла. Урыпҗыю 5—6 көн урнына, шулай ук, озакка тартыла: 15 нче августка бары 72 процент үтәлгән иде.

Әлки районы колхозларында, биредә күренгәнчә, агротехника чараларының кайберләре үз вактында үткәрелгән, икенчеләре, бөтенләй үткәрелмәгән. Биредә, билгеле, агрономия чараларының комплексы турында сүзнең булуы да мөмкин түгел. Һәм югары иген уңышы көтәргә урын да юк. Нәтиҗәдә, алдынгы районнар һәрбер гектардан уртача 9,5 центнер иген уңышы алганда, Әлки районы колхозлары бары 5,1 центнер уңыш алдылар.

Авыл хуҗалыгы алдынгылары, стахановчылары агрономия фәнен һәм практикасын күп алга этәрделәр. Алар агрономия чараларының күп кенә яңа төрләрен уйлап чыгардылар. Авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә катнашкан күп кенә ударниклар һәр кемгә билгеле булган һәм күп куллана торган агротехника чараларын үткәрү нигезендә югары иген уңышы алуга ирештеләр. Әгәр дә без һәм безнең колхозларыбыз Наркомзем тарафыннан күрсәтелгән агротехника чараларын тулысынча үтәгән булсалар иде, без, һич шиксез, 1,5—2 тапкыр артык иген уңышы алган булыр идек. Кызганычка каршы, бездә агрономия чараларын бик начар кулланалар әле.

Мин 1940 нчы елда үткәрелергә тиеш булган яңа агротехника чараларына тукталып үтәргә уйлыйм. Үткән елны хөкүмәтебез тары уңышын күтәрү бурычын куйды. Моның өчен күп кенә чаралар да эшләнде. Быел СССР Наркомземы һәм авыл хуҗалыгы академиясе тарафыннан карабодай уңышын күтәрү бурычы куела. Безнең алга, 10 мең гектар җиргә, үткән елларга караганда, 50 процент кимрәк чәчеп, һәрбер гектардан уртача 12 центнер карабодай уңышы алу бурычы куелды.

Мин уйлыйм, безнең бу алдынгылар киңәшмәсе иген уңышын күтәрү буенча булган тәҗрибәләрне туплар һәм иген уңышын тагын да күтәрү буенча конкрет чаралар билгеләр. Һәм без, сезнең белән бергә, тагын да күбрәк һәм яхшырак иген уңышы алырга ирешербез.

Иптәш Трутнев реченнән

(Норлат районы „Строитель“ колхозының хата-лаборатория мөдире)

Партиябез һәм хөкүмәтебез социалистик авыл хуҗалыгы алдына ел саен 8 миллиард пот ашлык җитештерү бурычын куйды. „Строитель“ колхозы иген уңышын күтәрүдә зур урын тоткан җирле һәм минераль ашламаларны куллану буенча тәҗрибәләр ясау эшен миңа йөкләде. Югары иген уңышы алу буенча тәҗрибәләр ясау өчен, барыннан да элек, белем, бу эшне ярату һәм үз көченә ышанып эшләү кирәк.

Без 1937 нче елны ашламасыз участкыларда арышның һәр гектарыннан 15 центнер уңыш алдык, ә һәрбер гектарга 20 тонна торф һәм 20 тонна тирес кертү нәтиҗәсендә, гектарыннан 20 центнер уңыш алынды. Тирес белән ашланган 7 га мәйданда тар рәт белән чәчү һәр гектарына 25 центнер уңыш бирде. 20 тонна торф һәм 20 тонна тирес белән ашланган мәйданда язгы бодай һәр гектардан 30 центнер уңыш бирде.

1939 нчы елны ашламасыз чәчелгән арыштан һәр гектарына 9,5 центнер, ә торф һәм тирес белән ашланган җирдә 14 центнер уңыш алынды. Язгы бодай ашламасыз җирдә 5,5 центнер, ә торф белән ашланган җирдә 10,25 центнер уңыш бирде. 2,5 центнер суперфосфат белән ашланган 22 гектар мәйданда язгы бодайның һәр гектарыннан 20,8 центнер уңыш чыкты. 1 центнер калий тозы белән ашланган 6 гектар мәйданда һәр гектарыннан 24 центнер уңыш алынды.

Менә бу тәҗрибәләр, җирле ашламалар куллану иген уңышының күтәргәнлекне күрсәтәләр.

КИҢӘШМӘ КӨНДӘЛЕГЕ

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсендә, 29 нчы январьдагы кичке утырышта фикер алышулар дәвам итте.

Акташ МТС тракторчылары бригадиры иптәш Әглямов югары иген уңышы өчен көрәштә авыл хуҗалыгы машиналарының гаят зур роль уйнавын күрсәтте. Ул үз бригадасының эшеннән күп фактлар китерде.

— Без 1939 нчы елны һәр трактор белән уртача 1.390 гектар эшләдек. Без моңа трактор техникасын яхшы белү, аны җентекләп өйрәнү һәм тракторлардан тулысынча файдалану нәтиҗәсендә ирештек. Үткән елны ирешелгән уңышларны нығытырга, 1940 нчы елны безнең тракторчылар һәрбер трактор белән 1.500 гектар эшләргә сүз бирделәр. Без үз йөкләмәбезне төгәл үтәрбез, ди иптәш Әглямов.

Терлекчелек тәҗрибә станциясенең сыер савучысы иптәш Юсупова стахановчылык хәрәкәтенен әледән - әле киң колач белән җәелүе турында сөйли. Ул 1939 нчы елны үзенә беркетелгән һәрбер сыердан 4.900 литр сөт алуга иреште. Иптәш Юсупова терлекчелектән тагын да зуррак доход алырга, стахановча эшләп хезмәт җитештерүчәнлегенең янадан-яңа күтәрелешен тудырырга сүз бирә.

Норлат районының „Строитель“ колхозы хата-лаборатория мөдире иптәш Трутнев югары иген уңышы өчен көрәштә тәҗрибә эшенең бик зур урын тотуы турында күп фактлар китерде.

Тымытык МТС ы комбаенчысы иптәш Дәүләтшин үзенең речендә түбәндәгеләрне әйтте:

— Мин 1937 нче елдан бирле комбайнчы булып эшлим. Катлаулы техниканы яхшы үзләштердем. Шуның белән бергә мин үз тәҗрибәмне системалы рәвештә башкалар белән уртаклашып килэм. Комбаенчылар үзләренә тапшырылган заданиеләрне үтәүгә намус белән карыйлар. Мин үткән елны үз комбайным белән 985 гектар урып-җыйдым. Ягулыкка 600 килограмм экономия ясадым. Һәрбер комбайнчы мин биргән күрсәткечләргә ирешә ала. Биредә үтеп чыга алмаслык бер төрле дә читенлек юк. Комбайнны озын көн буе эшләтү өчен мин заправканы төнлә ясыйм. Урып-җыюга керешү алдыннан участкыны үзем сайлап алам. Менә мондый чаралар үзләре генә дә комбайннан тулы файдалануга зур мөмкинлек бирәләр.

Киңәшмә трибунасында Акташ районының Чумаков исемендәге колхоз члены—звено башлыгы иптәш Домнина. Ул техник культуралар турында, даими звеноларның үрнәкле эшләре турында һәм мондый даими звеноларны һәрбер колхозда оештырырга кирәклек турында сөйли. Аның звеносы киндерчелектән югары уңыш алды. Ул моңа агротехника чараларын киң күләмдә куллану аркасында иреште. Иптәш Домнина быел киндерчелектән югары доход алырга сүз бирә. Моның өчен безнең участкы тулысынча хәзерләнде, ди ул.

Иптәш Прохоров (Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариаты) агротехника чараларының барсын да кулланганда гына югары иген уңышы алырга мөмкин булуын күрсәтә. Бу эштә кайбер районнарда зур җитешсезлекләр барлыгын тәнкыйт итә. Әлки районында агротехника чараларының барысын да куллану өчен көрәшнең гадәттән тыш йомшак булуын бик зур җитешсезлекләрнең берсе дип саный. Мондый факт бер Әлки районында гына түгел, әлбәттә. Иптәш Прохоров 1940 нчы елны югары уңыш алу өчен агротехника чараларын бик киң кулланырга киңәшмәгә катнашучыларны чакыра.

Мамадыш районының „Хәсанша“ колхозы председателе иптәш Казыйханов колхозны большевистик, колхозчыларны таза тормышлы итү өчен көрәштә ирешелгән уңышлар турында бик күп фактларга бай булган речь белән чыга. Бу колхоз үткән елны һәрбер гектардан 13 центнердан артык уңыш алды. Колхоз язгы чәчүне 7 көн эчендә төгәлләде. Тирес чыгару, кар тоту, туңга сөрү һәм башка шундыйларның планын арттырып үтәде. 1940 нчы елны бу колхоз һәрбер гектардан 20 центнер уңыш алырга сүз бирде. Иптәш Казыйханов: „Без үз йөкләмәбезне большевистик энергея белән үтәрбез. Быел һәр гектардан 20 центнер уңыш алу өчен барыгызны да социалистик ярышка чакырам“ ди.

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсенең кичке утырышы шуның белән тәмам булды.

*

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсенең кичә иртәнге утырышында беренче сүз Кукмара районы, Сталин исемендәге колхоз бригадиры иптәш Ишмөхәметовка бирелә. Ул үз бригадасында җитенчелектән югары доход алу буенча ирешкән уңышлары турында сөйли. 1940 нчы елны җитенчелектән тагын да зуррак доход алу өчен бөтен бригадасы белән нык көрәшергә сүз бирә.

Иптәш Вәлиев (ВЛКСМ ның Татарстан Өлкә Комитеты) социалистик авыл хуҗалыгының тагын да чәчәк атуы өчен, иптәш Сталинның якындагы еллар эчендә һәр ел саен 8 миллиард пот ашлык җинап алу турындагы тарихи күрсәтмәсен тулы үтәү өчен, 1940 нчы елны Сталинчыл югары уңыш алу өчен көрәштә комсомол оешмаларының бурычларына тукталып үтә. Алдынгы комсомолецларның гаят зур энергия белән көрәшеп, югары уңыш алуга ирешүләре, сокланырлык үрнәк күрсәтүләре, стахановча эшләүләре, яңалыкларны башлап йөрүләре, агротехника чараларын төгәл тормышка үткәрүләре турында бик күп мисальләр китерә. Механизатор кадрлар хәзерләү эшенә аеруча игтибар бирергә кирәклекне күрсәтә һәм Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариатының бу әһәмиятле эшкә тиешенчә игтибар бирмәвен тәнкыйтли.

— Агротехника укуларын оештыру, аларны кирәкле әдәбият белән тәэмин итү буенча да Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариаты йомшак көрәшә. Шушы көнгә кадәр агротехника программасы басылып чыкканы юк. Ә бу программаны китап рәвешендә басып чыгарырга бик күптәннән вакыт инде, ди иптәш Вәлиев.

Киңәшмә трибунасына Норлат районының „Кызыл Урманчы“ колхозы члены иптәш Тимершина чыга. Ул колхозның иң алдынгы стахановчысы булып санала. Иптәш Тимершина 1940 нчы елда югары иген уңышы алу өчен көрәштә барлык колхозчыларга үрнәк күрсәтә. Яхшы эшләве өчен колхоз аны ике тапкыр бүләкләде.

Чувашстан республикасының Чкалов МТС ы трактор бригадасы бригадиры иптәш Северов сүз ала. Ул бригадир булып эшли торган МТС үткән елны Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашты. МТС җиңел автомашина, 10 мең сум акча һәм беренче дәрәҗәле диплом белән бүләкләнде.

— Мин 6 елдан бирле бригадир булып эшлим. Үткән елны безнең бригаданың һәрбер тракторы 2.170 гектар эшләде. Ягулыкка 9.200 килограмм экономия ясалды. Хезмәт җитештерүчәнлегенең бу югары күрсәткечен без ничек ирештек соң? Техниканы бик яхшы үзләштерү, социалистик ярышны киң җәелдерү, стахановча эшләү нәтиҗәсендә ирештек. Безнең тракторчылар быел тагын да зуррак задание кабул иттеләр: һәр трактор белән 2.700 гектар эшләргә сүз бирделәр. Бу задание тулысынча үтәлер. Без үрнәкле эшләү өчен алдан большевистик хәзерлек күрәбез. 1 нче январьга барлык тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясадык. Безнең бригада бөтен Чувашстан күләмендә беренче урынга чыкты. Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашу өчен бригада членнарыннан 8 тракторчы кандидат булып расланды, ди иптәш Северов.

Лаиш районының „Путь Ленина“ колхозы хата-лаборатория мөдире иптәш Моденов тәҗрибә эшләренең бик яхшы нәтиҗәләр бирүен күрсәтә. Арыш ужымын тукландыру нәтиҗәсендә һәрбер гектардан 2 центнер 37 килограмм артык уңыш алынды. Кар тотылган участкыда да шундый ук хәл. Кар тотылган участкының һәрбер гектарыннан 18 центнер 8 килограмм арыш җыеп алынган булса, кар тотылмаган участкының һәрбер гектарыннан бары 14 центнер 8 килограмм гына уңыш алынды.

— Кар тотучыларның хезмәтен дөрес оештыру зур роль уйный. Без аларның хезмәт көннәрен тотылган карның калынлыгына карап исәплибез, ди иптәш Моденов.

Татарстан колхозларында күксагыз чәчү практикасы ел саен зур урын ала бара. Моның әһәмияте бик зур. Бу турыда Октябрь районының Нәриман исемендәге колхоз члены—звено башлыгы иптәш Ибраһимова күп фактлар китерә.

Ефремовчылар хәрәкәтенә киң тукталып ВКП(б) Өлкә Комитетының авыл хуҗалыгы бүлеге инструкторы иптәш Шибдин зур речь белән чыкты. Ул ефремовчыларның гектарыннан 70—80 центнер уңыш алулары турында конкрет мисальләр китерә.

Татарстан селекция станциясенең гыйлми сотрудниго иптәш Аетовның рече аеруча кызыксындыру тудырды. Селекция станциясе Буа, Буденный һәм башка районнарда бик файдалы тәҗрибәләр үткәргән. Мәсәлән, Буа районының байтак колхозларында орлыкның сортын яхшырту өчен ашлыкның сабагына, төбенә, тармакларына карап иң эре башаклар җинап алу практикасы киң кулланыла. Шулай ук киң рәтле чәчү аркасында да байтак колхозлар югары уңыш алдылар. „Коминтерн“ колхозы киң рәтле итеп чәчелгән участкының һәр гектарыннан 26 центнер, Каганович исемендәге колхоз 19 центнер уңыш алды. Бу районда люцерна чәчү эше дә елдан-ел арта бара.

Киңәшмәнең бу утырышында тагын түбәндәге иптәшләр речь белән чыктылар: Гәрәев (Юртыш МТС ы директоры), Гензбург (Татарстан Сәламәтлек Саклау Халык Комиссары), Емельянова (Аксубай МТС ының хатын-кызлардан торган тракторчылар бригадиры) һәм башкалар.

Сөйләнмәгән речьләр

(Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсе залыннан)

Трибунага Чувашстан республикасы, Вурмар районы, Сталин исемендәге колхоз председателе иптәш Н. Жарков чыгып басу белән зал, кинәт, җанлы хәрәкәткә килде. Делегатлар бер-берләренә карашып алдылар, урынарын җайладылар, гәүдәләрен аз гына алга табарак иделәр, һичбер сүзсез-нисез, бары тик күз карашлары белән генә, үзләренең күршеләрен тынычлыкка өндәделәр.

Зал тынып калды.

Оратор башлады.

Менә ул, делегатларны Сталин исемендәге колхоз белән таныштырырга тотынды. Ә бу колхозга бөек даһиның исеме тиккә генә бирелмәгән, күрәсең. Саннар һәм фактлар берсеннән-берсе кызыклар:

— Безнең үзебезнең радио узелыбыз, электр станциябез, бала тудыру йортыбыз, тавышлы кинобыз бар...

Зал җиңел генә гөжләп ала:

— Үзебезнең тавышлы кинобыз бар диме?—дип сорый бер делегат күршесеннән.

— Тукта әле, тукта...—дип янадан тыналар алар.

— Без быел 160 мең сумлык ашлама алырга булдык һәм аның 450 тоннасын ташып та куйдык инде,—дип дәвам итә иптәш Жарков.

— 160 мең сумлык! Ай-һай, бу бит безнең районга җитәрлек ашлама,—дип сөйләшәләр Чепья районы делегатлары.

Ахырда Сталин исемендәге колхозның Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашып беренче дәрәҗәдә диплом, җиңел автомобиль һәм 10 мең сум акча белән бүләкләнүе билгеле була.

— Алай!—дип сузып куялар делегатлар.

Бу, авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсендә сөйләнгән бер речьнең кайбер өземтәләре. Бу речьнең сере, аның фактларга байлыгында гына түгел, ул залда сөйләнмәгән речьләр тудырды. Мәсьәлә бит болай.

Безнең орденлы республикабыз быел һәрбер гектардан 100 пот иген уңышы алу өчен Чувашстан, Мордовия республикалары белән ярышка чыга. Бу ярышка чыгу шушы киңәшмәдә тикшерелә. Еу, алар белән безнең ярышуыбыз. Шунлыктан иптәш Жарков рече киңәшмә делегатлары өчен аерата кызыклы, һәм аерата көтеп алынган речь иде. Ярыш яланына чыгасың икән, кем белән ярышуыңны белү һәр кем өчен кирәк бит. Һәм зал Жарковны шушы ярышучы республика вәкиле сыйфатында тыңлады. Киңәшмә делегатлары кем белән ярышачакларын чынлап торып төшенделәр. Делегатларның берсе моны залда утырганда ук әйтте:

— Алар бит юл төзүдә дә Союз күләмендә беренчелекне алдылар. Алар Канаш станциясеннән 450 тонна ашлама ташыганнар икән, шул төзек юл аркасында җиңелгә килгән инде ул.

Менә киңәшмәнең тәнәфес вакыты. Һәр кем әле генә залда сөйләнгән речьне телгә ала һәм шул турыда сөйли. Мәкаләбезнең башында әйтелгән „Сөйләнмәгән речьләр“нең ияләре менә шушылар була инде. Әйе, болар киңәшмә залында сөйләнмәгән речьләр. Ләкин алар шунда сөйләнгән речьләр тәэсире астында барлыкка килгән речьләр.

Без биредә күңелләрендә әнә шундый ялкынлы речьләр туган ике генә кешене алабыз. Аларның берсе—Әтнә районы, Наянгыш авылының „Автодор“ колхозы члены, ат караучы Хәким агай Халиков. Икенчесе—Әлкәй МТС ының тракторчысы иптәш Камалова. Берсе, әйткәнебезчә, ат караучы, берсе—тракторчы. Алар бергә сөйләшәләр. Аларның бергә туры килүе никадәр матур очрашу! Хәким агай Камаловага ат турында сөйли, Камалова Хәким агага трактор турында сөйли.

Хәким агай әйтә:

— Трактордан файдаланганда атны онытмаска, аттан файдаланганда тракторны онытмаска кирәк. Башта, колхозлашуның беренче елларында кайбер ахмаклар моның киресен аңлатырга, ягни колхозчыларны аттан биздерергә маташтылар. Ул барып чыкмады, мондый магнәсезлеккә юл да бирелмәде,—ди. „Ир канаты—ат“, ди,—ат булмаса, бер кая да бара алмыйсың кызым,—ди.—Трактор да шулай,—ди.—Ат белән генә эш бармый, һәм гел трактор белән генә дә бармый, икесе дә кирәк, икесе дә кадерле. Бу турыда—атлар санын 35 процентка арттыру турында иптәш Сталинның да сүзе булды бит,—ди.

Камалова әйтә:

—Дөрес сөйлисең бабай,—ди. Кабатлап,—бик дөрес сөйлисең,—дип куя.

Карт тагын әйтә:

— Дөрес сөйлим шул,—ди.— Мин үзем ат карауч, ә малаем минем тракторчы,—ди.—Ягни,—ди—машина күбрәк белүне сорый, шуның өчен ул эш яшьләргә кулай. Менә сезгә кулай, ә атны аны без картлар карарга тиешлебез, без аны яхшы беләбез,—ди. — Менә син тракторчы. Син тракторны беләсең, ә мин ат караучы атны нык беләм,—ди. Камаловага бераз карап торгач тагын сүзен башлый:

— Аркалык күтәренке булса—ат буыла. Төшенке булса—атның муйнына камыт суга. Ә инде аркалык артта булса—ул вакытта атның җилкәсенә ыңгырчак суга,—ди.

Камалова аның сүзен куәтли:

— Трактор да шулай, карамыйча йөртсәң, ул да буыла,—ди.

Бабай көлеп җибәрә. Камалова исә сүзеннән туктамый:

— Тракторның хикмәте, аны чиста йөртүдә. Тракторны аппак борын яулыгы белән сөртсәсен икән, ул борын яулыгы аппак килеш калырга тиеш.—Менә мин быел сезонга 700 гектар эшләргә йөкләмә алдым. Аны ватык трактор белән үтәп булмый бит,—ди.

— Дөрес, шулай ук аксак ат белән дә үтәп булмый андый зур эшне. Трактор да гөрләсен, атлар да көшнәсен, — дип аңа кушыла карт.

Президиумнан звонок шалтыраганы ишетелә. Камалова ашыга-ашыга залга таба атлый:

— Малаең тракторчы булгач, миннән сәлам әйт аңа,—ди ул картка карап. Ә карт:

— Ярый, ярый, әйтермен,—ди дә безгә таба борыла:

— Шәп нәрсә булырга ошый. Москвада күргәзмәдә дә булган бит.

Ул аны текә баскычның башына кадәр озатып кала. Камалова артыннан баскычтан без күтәреләбез һәм карттан сорыйбыз:

— Күргәзмәдә син үзең булдыңмы соң?

— Үткән ел була алмадым. Болай бездән булдылар булуын. Безнең ферма мөдире барып кайтты.

— Ә быел кем барачак?

— Быелгысын хәзергә әйтеп булмый әле. Анысы—алда. Без юк исә Закирҗаннар, Шиһаплар белән көн саен диярлек дворда күргәзмә турында сөйләшеп утырабыз. Белеп булмый, безнең баруыбыз да бик мөмкин. Безнең атлар тирә-юндә иң яхшы,—ди.

Күрәсез, сөйләнмәгән бу речьләр никадәр бай эчтәлекле!

Гариф Галеев.

СЕДОВЧЫ ГЕРОЙЛАР—ТУГАН ҖИРЕБЕЗДӘ

МАКТАУЛЫ ЗАДАНИЕ ҮТӘЛДЕ

СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ И. Д. ПАПАНИН БЕЛӘН БЕСЕДА

„И. СТАЛИН“ БОЗВАТКЫЧЫ БОРТЫ, 29 январь. (Радио ТАСС). Матбугат вәкилләре белән беседасында „Г. Седов“ бозваткычын чыгару экспедициясе начальнигы Советлар Союзы Герое И. Д. Папанин болай диде:

— Бүген „Иосиф Сталин“ бозваткычы коллективы „Г. Седов“ бозваткычын Гренландия диңгезе бозларыннан чыгару буенча мактаулы заданиене үтәве турында партиягә һәм хөкүмәткә, иптәш Сталинга һәм иптәш Молотовка рапорт бирде. Легендар Совет карабы Мурманск портына китерелде, Советның 15 патриоты туган җиргә кайттылар.

Флагман бозваткычы морякларыиптәш Сталинның мактаулы заданиесен гаять зур энтузиазм белән үтәделәр. Арктика линкоры Мурманскидан төньякка таба нак хөкүмәт билгеләгән срокта чыгып китте. Безне алда зур кыенлыклар көтә иде. Бөек Сталин исемендәге бозваткычның экпедициясе һәм командасы һичбер масаймыйча, „Г. Седов“ка бару юлындагы гаять зур тоткарлыкларга нык игтибар биреп, стихиягә каршы көрәшкә бардылар. Диңгез бозваткычны 10 балл көчендәге шторм белән каршылады. Шторм берничә көннәр дәвам итте. Флагман карабы коллективның барлык көчләрен җигеп, шторм һәм давыл аркылы үтеп, озаклamый бозлар эченә барып керде. 80 нче градус 32 нче минутта караб үтә алмаслык боз кырларына очрады. Боларга каршы көрәш карабның күмер запасларын бетерүе мөмкин иде. Без тирәнгә разведка ясау белән чикләндек. Бу разведка безгә бозларның ни хәлдә икәнлеге турында кирәкле материалларны бирде. Аннары караб Баренцбургка таба китте һәм күмер алганнан соң яңадан төньякка таба юнәлде.

3 нче январьда седовчылар безнең прожекторларның утын күрделәр. Тагын 2 көн үткәч төн караңгылыгында „Седов“ның ялтыраган уты күренде. Флагман карабы 10 көн буена бик тырышып һәм бер-бер артлы, әле каршыга атака ясап, әле әйләнеп үтеп, „Седов“ юлына аркылы төшкән өч еллык бозларны үтте. 11—12 нче январьда безне бозлар бик нык китереп кыстылар. Без карабны сугышчан хәзерлек хәленә китерергә, аварие запаслары хәзерләргә мәҗбүр булдык. Караб бу авыр сыналудан үтте. Икенче көнне бозларның торышы үзгәрде. Караб бозларга яңадан һөҗүм итә башлады һәм 13 нче январьда 12 сәгат 07 минутта „Седов“ка барып җитте.

Партия һәм хөкүмәт заданиесенең беренче өлеше әнә шулай үтәлде.

Карабның 81 нче параллель артына походы Совет котыпчыларының әгәр дә кирәк булса, үзләренең гүзәл карабларында кыш көне дә югары киңлекләргә үтә алуларын күрсәтте.

15 нче январьда ике бозваткычның коллективлары Сталин һәм Молотов иптәшләрдән котлаулар алдылар. Болар онтылмаслык котлаулар иде һәм алар безгә яңа көч бирделәр. Иптәш Сталинның игтибары белән рухланган хәлдә без партия һәм хөкүмәт заданиесенең икенче өлешен дә, беренче өлеше кебек үк уңышлы рәвештә үтәргә вагдә бирдек.

Мең тонна авырлыктагы бозлар арасына кереп каткан „Седов“ны чыгару буенча гаять катлаулы операция 16 нчы январьда башланды. Ул көнне без Ватаныбыз ярларына таба кайта башладык. Бозларны шартлатып һәм „Седов“ның корпусын җылытып, без карабны аның белән бергә йөзеп килгән бозларның бер өлешеннән азат иттек. Флагман карабы боз кырыена бик авырлык белән үтте. Калын буксир канатлары гаять көчле нагрузкага түзә алмадылар һәм бер-бер артлы өзелделәр. Тик Баренцбургка бару юлында гына караблардан бозлар бөтенләй кубып төштеләр.

Баренцбургда боз ваткычлар 3 көн тордылар һәм Арктика флоты өчен кирәк кадәр күмер алдылар. Безгә ашыгырга кирәк иде, чөнки синоптиклар көчле давыл булачакны хәбәр иткәннәр иде. Мондый давыллар вактында „Седов“ны буксирда алып бару гаять кыен булачак иде. 25 нче январьга каршы төндә „И. Сталин“ һәм „Г. Седов“ кунакчыл Баренцбургдан киттеләр һәм илебез ярларына таба юлга чыктылар.

Караблар Шпицберген ярлары буендагы юка бозлар арасыннан бардылар. Бу поход бик авыр метеорология шартларында үтте. Караблар ике циклон арасындагы тар коридордан бардылар. Циклоннарның үзгәрүенә карап, юлны да үзгәртеп барырга туры килде. Дүртенче тәүлек тулганда алда Зур Җир ярлары күренде. Тагын берничә сәгаттән без Мурманск портына килеп туктадык. Поход тәмам булды. Сталин заданиесе үтәлде.

Ватаныбыз үзенең улларын шатлык һәм ягымлылык белән каршы ала. Седовчылар туган илләренә җиңүчеләр булып кайттылар. Аларның батырлыкларын безнең илебез генә түгел, бәлки Совет котыпчыларының яңа гүзәл җиңүенә сокланучы бөтен алдынгы һәм прогрессив кешелек дөньясы чын күңелдән котлый.

„Седов“ның тарихи язмалары, күп томнарча фәнни эш материаллары әле өйрәнелмәгән, ләкин тиңдәшсез хәрәкәтнең нәтиҗәләре Совет фәненә нинди кыйммәтле хәзинә икәнлеге хәзер үк ачык инде. „Г. Седов“ бозваткычы хәрәкәтенең материаллары фәнни яктан гына түгел, бәлки практик яктан да әһәмиятле. Алар Арктикада бара торган процесслар турындагы безнең белемнәребезне арттырырлар, Төньяк диңгез юлындагы бозларның нинди хәлдә икәнлеген тагын да дөресрәк итеп алдан әйтергә мөмкинлек бирерләр һәм Котып бассейны диңгезләрендә йөзүне җиңеләйтерләр.

„И. Сталин“ бозваткычы диңгезгә чыгарга тулы хәзерлек хәлендә тора һәм аның командасы нинди генә минутта булса да мактаулы яңа вахтага басар. Без Совет котыпчыларының үзләренә күрсәтелгән ышанычны аклаганлыклары турында партиягә һәм хөкүмәткә рапорт бирүне бәхет дип саныйбыз. Әгәр дә партия, хөкүмәт һәм иптәш Сталин безгә сөекле Ватаныбыз даны өчен яңа заданиеләр тапшырса, без горурланырбыз һәм чиксез шат булырбыз.

„И. Сталин“ бозваткычы Гренландия диңгезендә. РӘСЕМДӘ: экспедиция начальнигы иптәш И. Д. Папанин бозваткыч боцманы иптәш Мишинга бойрык бирә. Д. Дебабов фотосы (ТАСС фото-клишесе).

„И. СТАЛИН“ һӘМ „Г. СЕДОВ“ БОЗВАТКЫЧЛАРЫ МУРМАНСК ПОРТЫНДА

... Легендар „И. Сталин“ һәм „Г. Седов“ бозваткычлары бүген кич илебез ярларына, Мурманск портына килеп җитәчәкләр диган хәбәр шәһәрдә бик тиз таралды.

Урамнарда иртәдән үк гадәттән тыш җанлылык. Һәр кайда да бөек Сталинның, партия һәм хөкүмәт җитәкчеләренең, Советлар Союзы Герое иптәш Папанинның һәм 15 батыр седовчының рәсемнәре. Һәр кайда да кызыл флаглар. Урамнар бәйрәмчә киенгән кешеләр белән тулган.

Портка җыелган меңнәрчә кешеләр тирән тәэсирләнү хисе кичерәләр. Якынлашып килүче бозваткычларның героик экипажларын алар зур күтәренкелек һәм көчле кул чабулар белән каршылыйлар. „Ура“ тавышлары портның бер читеннән икенче читенә кадәр яңгырый.

18 сәгат. Бозваткычлар портка килеп җиттеләр. Данлыклы 15 седовчы геройлар ярга чыгалар...

Портта куелган трибунага үзләренең семьяләре белән берлектә седовчылар, „И. Сталин“ бозваткычы экипажының членнары, Мурманскидагы җәмагат оешмаларының вәкилләре киләләр.

„Интернационал“ тавышлары астында тантаналы митинг ачыла.

Партиянең Мурманск Өлкә Комитеты һәм шәһәр комитеты секретаре иптәш Старостинның кереш речennән соң Төньяк Диңгез Юлы Баш Идарәсе начальнигы, СССР Верховный Советы депутаты, Советлар Союзы Герое И. Д. Папанин сөйли. Ул болай ди:

— Моннан ай ярым элек большевистик партиябезнең Үзәк Комитеты, ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы, безгә 15 Совет патриотын, героик „Г. Седов“ карабын рәхимсез Арктиканың бозлар тоткынлыгыннан алып чыгуны тапшырып, зур ышаныч күрсәттеләр. Бу карабта совет кешеләреннән торган кечкенә генә коллектив рәхимсез Арктикага каршы каты көрәш алып барды һәм җиңеп чыкты...

Туган илебез ярларыннан киткәндә үк инде без үзебезнең җиңәчәгебезгә ышанган идек. Безнең җиңүгә булган омтылышыбызны бер нинди дә давыллар һәм Котып төннәре бастыра алмады. Чөнки безне, совет кешеләрен, большевиклар партиясе һәм совет халкының бөек җитәкчесе иптәш Сталин тәрбияләгән...

Яшәсен җиңелмәслек Кызыл Армиябез һәм Хәрби Диңгез Флотыбыз!

Яшәсен бөек Совет Хөкүмәте һәм аның башлыгы иптәш Молотов!

Яшәсен Ватаныбызның большевистик җиңүләрен оештыручы һәм аларның җитәкчесе бөек иптәш Сталин!

Иптәш Папанин бу сүзләрне әйткәндә мәйданда көчле „Ура“ тавышлары яңгырый.

Героик бозваткыч „Г. Седов“ның помполиты иптәш Д. Г. Трофимовка сүз бирелә:

— Бүген, без Совет җиренә аяк басканда, мин бөек Совет Хөкүмәтенә, большевистик партиябезнең Үзәк Комитетына һәм иптәш Сталинның үзенә тирән рәхмәт хисебезне белдерәм. Алар безгә, 15 котыпчыга, Төньяк Боз диңгезенең үзәк Котып бассейнында фәнни эш алып барырга мөмкинлек бирделәр. Бөтен хәрәкәт вакты буена без үз турыбызда хөкүмәтнең, партиянең һәм кадерлебез иптәш Сталинның даими кайгыртуын сиздек. Бу безне юлыбызда очраган барлык кыенлыкларны җиңүгә рухландырды...

Безнең сугышчан бурычыбыз фән өчен Боз океанынннан мөмкин кадәр күбрәк тәҗрибәләр алырга һәм карабны сакларга дигән бурыч иде.

Без үзебезнең сугышчан заданиебезне үтәдек,—ди иптәш Трофимов һәм аның бу сүзләре көчле кул чабуларга күмелә.

Легендар „Г. Седов“ карабының капитаны иптәш К. С. Бадигинга сүз бирелгәч кул чабулар яңадан көчәеп китәләр. Иптәш Бадигин болай ди:

— Иптәшләр, кадерле ватандашларым, мин сезне чын күңелемнән бөтен йөрәгем белән котлыйм. Шулай ук сезне минем барлык иптәшләрем дә—барлык седовчылар зур шатлык белән котлыйлар. Безнең хәрәкәт тәмам булды. Аның төп йомгагы шуннан гыйбарәт ки, без совет кешесенең, большевикның, социалистик Ватан патриотының нәрсәләргә сәләтле икәнлеген бөтен дөньяга тагын бер кат күрсәттек.

Безне большевистик партиябез тарафыннан җитәкләнүче Ватаныбыз алып барды, үзенең кайгыртучанлыгы белән безне иптәш Сталин рухландырды. Без тыныч булдык, чөнки иптәш Сталин совет кешеләре турында бер кайчан да онытмый.

Хәрәкәтебез вактында без иптәш Сталиннан һәм иптәш Молотовтан аталарча кайгыртучанлык белән тулы булган, ягымлы өч радиограмма алдык...

Митингта катнашучыларның шатлыклы тавышлары астында иптәш Бадигин үзенең речен түбәндәге сүзләр белән тәмам итә:

— Безнең бөек Совет Ватаны чәчәк атсын һәм яхшырсын!

Куәтле Ленин—Сталин партиясе тагын да ныгысын!

Бөек остазыбыз һәм дусыбыз иптәш Сталин күп еллар яшәсен!

Аннары лейтенант иптәш Я. Т. Исаенко сөйли. Аның артыннан Төньяк Диңгез Юлы Баш Идарәсенең судоремонт заводы прорабы иптәш Гущин седовчыларны Мурманск хезмәт ияләре исеменнән котлый.

Легендар геройлар һәм ялкынлы патриотлар—седовчылар хөрмәтенә, Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) Партиясе хөрмәтенә, атабыз һәм остазыбыз сөекле Сталин хөрмәтенә булган көчле алкышлар мәйданда еракларга яңгырый. Сталин һәм Молотов иптәшләргә котлаулар җибәрергә тәкъдимнәр керә. Бу тәкъдимнәрне шатланып каршы алалар.

Митингта катнашучылар Сталин һәм Молотов иптәшләргә җибәреләчәк котлауларның текстын зур күтәренкелек белән кабул итәләр.

Мурманск, 29 январь. (ТАСС).

„И. Сталин“ бозваткычының капитаны иптәш М. П. Белоусов. Д. Дебабов фотосы (ТАСС фото-клишесе).

Безгә—бәхетле Совет Белостогына килегез!

БЕЛОСТОК, 29 январь. (ТАСС). Шәһәрнең хезмәт ияләре данлыклы седовчы геройларның Зур Җиргә кайтып керүләре турындагы хәбәрне зур шатлык белән каршыладылар. Урамнарда, эшче клубларында, предприятиеләрдә радиорупорлар янына меңнәрчә кешеләр җыелды һәм алар Папанин, Бадигин, Трофимов һәм башка иптәшләрнең радио буенча Мурманскидан тапшырылган речьләрен гаять зур игтибар белән тыңладылар. Кич белән 1 нче номерлы текстиль комбинатында, седовчыларның туган җиргә кайтуларына багышлап, зур митинг булды.

Эшче хатын иптәш Дынович митингта болай диде:

— Без, Белосток текстильчеләре, үзебезнең батыр иптәшләребезнең, данлыклы совет котыпчыларының яңа җиңүгә ирешүләре белән горурланабыз. Бадигин, Трофимов һәм Ватанның тагын 13 данлыклы патриоты совет кешеләренең, совет баһадирларының нәрсәләргә сәләтле булганлыкларын бөтен дөньяга тагын бер тапкыр күрсәттеләр. Без, үзебезнең партиянең, хөкүмәтнең, даһи юлбашчыбыз иптәш Сталинның легендар хәрәкәттәге иң авыр минутта седовчыларга ярдәм күрсәтүләре белән горурланабыз. „И. Сталин“ бозваткычы хөкүмәт заданиесен мактаулы рәвештә үтәде.

Митингта катнашучылар бер тавыштан кабул ителгән резолюциядә түбәндәгечә яздылар:

„Сезнең җиңүегез безне яңа казанышларга, хезмәтнең җитештерүчәнлеген күтәрүгә, производство планнарын арттырып үтәүгә рухландыра, бездә сайлау кампаниясен иң яхшы итеп үткәрүгә рухландыра. СССР Верховный Советына һәм Белоруссия ССР Верховный Советына үзебезнең депутатларыбыз итеп халыкның иң лаеклы улларын һәм кызларын, совет халкының даны өчен теләсә нинди батырлыкларга сезнең шикелле үк сәләтле булган кешеләрне сайларбыз. Кадерле дуслар, безгә—азат һәм бәхетле Совет Белостогына килегез“.

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

Чит илләрдә

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

БЕРЛИН, 29 январь. (ТАСС). Германия информация бюросы, 27 нче январьда көнбатыш фронтында тынычлык хөкем сөрде, дип хәбәр итә. Рейн—Мозель арасындагы фронтның көнчыгыш өлешендә бераз гына артиллерия атышуы булган. Авиация хәрәкәтләре булмаган. Англиянең 3.554 тонна авырлыгындагы „Дидо“ пароходы һәм Голландиянең „Оттоланд“ пароходы минага бәрелгәннәр. Швециянең „Готиа“ пароходы Шотландия яры буенда баткан.

ПАРИЖ, 29 январь. (ТАСС). Сугыш хәрәкәтләре турында кичә кич белән иглан ителгән рәсми белдерүдә: „Фронтның кайбер участкыларында бүген алгы частьләрнең хәрәкәте яңадан башланды“ дип күрсәтелә.

Бүген иртә белән чыгарылган белдерүдә, фронтта „яңа бер нәрсәнең дә булмавы“ хәбәр ителә.

ЛОНДОН, 29 январь. (ТАСС). Англиянең авиация министрлеге, бүген Англиянең төньяк-көнчыгыш яры буенда һава тревогасы игълан ителгәнлекне белдерде. Ләкин бу районда бер нинди самолетлар күренмәгән.

БЕРЛИН, 29 январь. (ТАСС). Германия информация бюросының Ослодан хәбәр итүенә караганда, кичә Осло заливында Швециянең 2.699 тонна авырлыгындагы „Меларен“ пароходы белән Норвегиянең 1.657 тонна авырлыгындагы „Баута“ пароходы бәрелешкәннәр. „Баута“ пароходы баткан. „Меларен“ пароходы Ослога кире кайткан. Һәр ике пароходның командаларына зарар килмәгән.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

ҮЗӘК КЫТАЙДА

26 нчы январьда кытай артиллериясе Аньхуэй провинциясендә, сугыш кирәк-яраклары төягән хәлдә Янцзы елгасы буйлап бара торган япон транспортын тупка тотты. Транспорт батты.

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә кытай гаскәрләре Наньнин—Цинчжоу арасындагы шоссе юлында күп кенә пунктларны алдылар.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Шаньси провинциясенең көньяк-көнчыгыш өлешендә кытай гаскәрләре 24 нче январьда Байичэньны (Чжанцзыдан көньяк-көнчыгышка таба 30 километрда) алдылар. Бу секторда японнарның 20 мең кешегә якын гаскәрләре бар.

Суйюань провинциясендә японнарның Баотоу районында тупланган гаскәрләре 22 нче январьда Хуанхэ елгасын аркылып чыктылар. Ләкин, техника ягыннан японнарның өстен булуларына карамастан, алар шул ук көнне кичкә таба бик күп көчләрен югалттылар һәм кире чигенделәр.

АК ФИНЛЯНДИЯДӘ ТЫНЫЧ ГРАЖДАННАРНЫ МАССА КҮЛӘМЕНДӘ КУЛГА АЛУЛАР һӘМ АТУЛАР

СТОКГОЛЬМ, 29 январь. (ТАСС). Ак Финляндия шәһәрләрендә һәм авылларында Маннергейм бандалары эшчеләрне үтерәләр, йортларны яндыралар, тыныч гражданнарны үзләренең туган җирләреннән көчләп куып җибәрәләр.

Швециянең „Ню даг“ газетасы болай яза: „Ак Финляндиядәге хәл торган саен 1918 нче елныңык истә калган елны хәтерләтә. Меңнәрчә эшчеләр кулга алынган, йөзләрчә эшчеләр атылган. Куусинен җитәкчелегендәге Халык Хөкүмәтенә теләктәшлек күрсәтүдә шикләнелгән тыныч гражданнарны ак фин властьлары һичбер тикшерүсез һәм судсыз кулга алалар һәм аталар“.

Моңа кадәр ишетелмәгән дәрәҗәдәге террорга карамастан, Маннергейм палачлары тылда „тынычлык“ тудыруга ирешә алмадылар. „Ню даг“ газетасының хәбәр итүенә караганда, Выборг һәм Котка эшчеләре ак финнәрнең изүенә каршы ачыктан-ачык көрәшкә чыгалар. Финляндиянең бу ике эре промышленность үзәгендә җидди тәртипсезлекләр булган.

Хәзерге вакытта төньяк Норвегиядә булган фин качаклары Норвегиянең „Арбейтер“ газетасы хәбәрчесенә ак финнәр армиясендә хөкем сөрә торган массовый ризасызлык турында хәбәр иткәннәр. Хәбәрче түбәндәгечә яза: „Качаклар, ак фин властьларының күптән түгел генә фин солдатларыннан торган зур группаны кулга алганлыкларын һәм атканлыкларын сөйлиләр. Кулга алуларның һәм атуларның рәсми сәбәбе: „Шпионлык оешмасы табылу“. Гади телдә бу, ак финнәр армиясенең бик күп офицерлары һәм солдатлары таннерларның һәм маннергеймнарның авантюра политикасында катнашырга теләмиләр диган сүз. Фин гаскәриләренең бу группасының лидеры „үз-үзен үтерү мөмкинлеген алган“, ә калган 60 кеше атылган, алар арасында 3 хатын-кыз бар“.

Ак Финляндиянең тыныч гражданнарын моңа кадәр ишетелмәгән төстә мәсхәрәлиләр һәм талыйлар. Ул гына да түгел, Маннергейм бандитлары аларны туган җирләреннән көчләп куып җибәрәләр. „Ню даг“ газетасының хәбәр итүенә караганда, шюцкор погромчылары крестьяннәрнең киез итекләрен, туннарын, одеалларын, өске киемнәрен, эчке киемнәрен, балталарын, тимер кирәкләрен, пычкыларын, мотыгаларын һәм башка әйберләрен талап алалар.

КӨНЬЯК АФРИКА СОЮЗЫНДА ЯҢА ПАРТИЯ ОЕШТЫРЫЛДЫ

ЛОНДОН, 29 январь. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Көньяк Африка Союзы парламентында оппозиция лидеры Герцог белән милләтчеләр партиясе җитәкчесе Малан арасында берләштерелгән яңа партия оештыру турында килешүгә ирешелгән.

Көньяк Африка Союзында Англиягә бәйсез булган республика хөкүмәте төзү бу партиянең максады булып тора.

Фото-желатин заводының дирекциясе, парткомы һәм төзелеш комитеты 8 нче номер Кинопленка фабрикасының директоры

Иван Степанович

СМИРНОВ

ның шушы ел 28 нче январьда вакытсыз үлүе уңае белән тирән кайгы белдерәләр һәм фабрика коллективының һәм мәрхүмнең семьясенең кайгысын уртаклашалар.

Галиәсгар Камал исемендәге

Татар Дәүләт Академия театры

31 нче январьда, шулай ук 1 һәм 2 нче февральдә ПРЕМЬЕРА

БУЛАК АРТЫ „РЕСПУБЛИКАСЫ“

Талоннар: бүген 105. иртәгә 106.

Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

Татар Дәүләт Опера театры

Зур Драма театры бинасында
Бүген, 31 нче январьда

ФАЙДАСЫЗГА САКЛАНУ

Талоннар: 71 һәм 72.

Кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Культпоходлар оештыру буенча заявкалар алына. Телефоннар: 29—04 һәм 5—20.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

1 нче февральдә

БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА

Талон 89.

2 нче февральдә

РЕВИЗОР

Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана.

Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 8 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

БҮГЕН һӘМ һӘР КӨН

Москва 4 нче труппасының — соңгы гастрольләре —

ПОПУЛЯР КОМИК, һӘР ТӨРЛЕ ХАЙВАННАРНЫ ӨЙРӘТҮЧЕ,

РСФСР ның атказанган артисты орденлы **М. ЗОЛЛО** үзенең антропозоологик труппасы белән

Атнаның икенче көнендә цирк эшләми.

Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„Электро“—ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ. „Унион“—МИНИН һӘМ ПОЖАРСКИЙ. „Кызыл Йолдыз“—ДУСЛАР. „Чатки“—ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ. „Пионер“: көндез—ФЕДКА, кич—УКЫТУЧЫ. „Колхозник“ БАЙ КӘЛӘШ. „Рот-Фронт“—ДОКТОР КАЛЮЖНЫЙ. Культура Сарае—СТЕПАН РАЗИН.

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР, № А — 232 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 409.